ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

«25» декабрь 2025 ел

№ 46

**ТР Арча муниципаль районы «Урняк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктларында пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары уздыру чорында гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль милекне саклауны тәэмин итү максатларында, 1994 елның 21 декабрендәге №69-ФЗ «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 30 нчы маддәсе һәм 1993 елның 18 маендагы №1866-XXII «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 25 нче маддәсе нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.12.2024 елдан 08.01.2025 елга кадәрге чорда Татарстан Республикасы территориясендә аерым янгынга каршы режим кертү турындагы карарына ярашлы рәвештә, Урняк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Пиротехник эшләнмәләр куллану өчен рөхсәт ителгән урыннар итеп түбәндәгеләрне билгеләргә: п. Урняк – автодром территориясендә (Урняк торак пунктыннан 150 м көньякта); д. Казанка – Җиңү паркында (Казанка торак пунктыннан 200 м төньякта); д. Апайкина Гарь – футбол мәйданчыгында (Апайкина Гарь торак пунктыннан 150 м төньякта); с. Казанбаш һәм д. Кутук – Казанка елгасы буенда (Кутук торак пунктыннан 150 м көнбатышта); с. Иске Турналы – зират янында (Иске Турналы торак пунктыннан 150 м көнчыгышта); д. Алга-Куюк – зират янында (Алга-Куюк торак пунктыннан 200 м көнбатышта); д.Кече Турналы – буа янында (Кече Турналы торак пунктыннан 150 м көнбатышта);с. Урта Пшалым – иске мәктәпнең спорт мәйданчыгында (Урта Пшалым торак пунктыннан 150 м көньякта); с.Югары Пшалым – буа янында (Югары Пшалым торак пунктыннан 300 м төньякта); д. Түбән Пшалым – стадионда (Түбән Пшалым торак пунктыннан 150 м төньякта); с.Күлтәс – Күлтәсенька елгасы буенда (Күлтәс торак пунктыннан 150 м көнбатышта).

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннардагы мәгълүмати стендларда түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: п. Урняк, Лесная урамы, 44а йорт; Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт; Урта Пшалым авылы, Вахитов урамы, 15 йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Урняк авыл җирлеге башлыгы В.Р. Габделхаков

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ